ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ***

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***
***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ***

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

30 октябрь 2020 ел №1-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының 2009 елның 23 июлендәге 4-43 номерлы «Җир салымы турында» (алга таба-Карар) (2020 елның 25 февралендәге 1-53 номерлы,2020 елның 24 июнендәге 4-58 номерлы карарлары редакциясендә) карарына үзгәрешләр кертергә:

- Карарның 4 статьясындагы 1 пунктының 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә һәм расларга:

«1.3. Парклар, скверлар, һәйкәлләр, обелисклар, мәйданнар һәм башка гомуми кулланылыштагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата муниципаль бюджет, казна учреждениеләре җир салымын түләүдән азат ителә.»

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Буа шәһәре Башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов